Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

24 ноябрь 2025 ел № 2

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Яңгул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешенең, түбән керемле (80 яшькә җиткән) ялгыз өлкән яшьтәге пенсионерлардан, онкология авыруларыннан, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны, 2023 елдан Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салым суммасының 90% ы күләмендә ташламалар бирү белән, 2026 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү, коймалап алу;

- урамга яктырткыч җайланмалары урнаштыру.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә. baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Балтач районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р. Р.Гыйльфанов